**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2024 елның 1 августындагы 3208 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының
2024 елның 1 апрелендәге 1241 номерлы
«Казан шәһәре территориясендә урам сәүдәсен
һәм хезмәтләр күрсәтүне оештыру, аларның
объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында»гы
карарына үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Казан шәһәре прокуратурасының 2024 елның 3 июнендәге 02-08-02-2024/прдп12-24-20920048 номерлы протестын исәпкә алып **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 1 апрелендәге 1241 номерлы «Казан шәһәре территориясендә урам сәүдәсен һәм хезмәтләр күрсәтүне оештыру, аларның объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында»гы карарына, түбәндәге эчтәлекле 7 (1) пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«7(1). Әлеге карарны үтәмәгән өчен административ җаваплылык турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле органнар итеп Казан шәһәре Башкарма комитетының тиешле районнары администрациясен билгеләргә».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**